Муниципаль казна учреждениесе
«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»
(МКУ «Мәгариф идарәсе»)

# БОЕРЫК

2022 нчы ел 1 нче декабрь № 654 - ОД

Әгерҗе шәһәре

**Районкүләм V “Яшь белгеч” олимпиадасы нәтиҗәләре турында.**

2020-2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасын үтәү кысаларында, туган якның тарихы белән танышу, аны өйрәнү, Иж – Бубый мәдрәсәсе тарихын өйрәнүне дәвам итү, Мәгърифәтче Бубыйлар мирасын барлау, әйләнә-тирә дөнья, тарих, тормыш иминлеге нигезләре, рус теле, татар теле һәм әдәбияты, математика, физика, биология фәннәреннән укучыларның белемнәрен тирәнәйтү, функциональ грамоталылыкны үстерү максатыннан, Мәгариф идарәсенең № 614нче боерыгы нигезендә (2022 ел 15 ноябрь), 1 декабрьдә Әгерҗе районы Иж – Бубый урта гомуми белем бирү мәктәбендә районкүләм V “Яшь белгеч” олимпиадасы узды. Чарада 11 мәктәптән 4,5,6,7нче сыйныфтан 41 укучы катнашты (4нче сыйныф – 5 укучы, 5нче сыйныф – 13 укучы, 6нчы сыйныф – 13 укучы, 7нче сыйныф – 10 укучы). Ел саен катнашучы мәктәпләр һәм укучылар саны артуы күзәтелә. Жюри әгъзалары – Терентьева Л.М. (мәгариф идарәсе методисты), Абрамова Л.Р., Гараев Э.И., Альмукаева Г.Ю., Абзалиева А.Г., Латыпова Л.Р., Шульмина Л.Н., Ибраһимова Р.Х., Маннапова Э.Н., Гумарова А.А., тарафыннан эшләргә җентекле анализ ясалды. Биремнәр комплекслы, логик фикерләүгә, укучыларның гомуми үсешенә юнәлтелгән иде. Олимпиадага биремнәр “Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи-документаль җыентык” тан һәм Әгерҗе районына багышланган чыганаклардан алынып төзелде.

Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, 4нче сыйныф укучыларының югары әзерлекләре күренде. 4нче сыйныфта барлыгы 50 баллдан, иң югары балл – 50, иң түбәне - 10 балл, 5нче сыйныфларда барлыгы 30,5 баллдан, иң югары балл – 21,5, иң түбәне 11 балл, 6нчы сыйныфларда барлыгы 29 баллдан, иң югары балл – 21, иң түбәне 6,5 балл, 7нче сыйныфларда барлыгы 30,5 баллдан, иң югары балл – 21,5, иң түбәне 5 балл. 6,7нче сыйныфлар математикадан, рус теленнән, биремне уртача дәрәҗәдә башкарганнар. Иж – Бубый мәдрәсәсе, аның мөгаллимнәре, шәкертләре, Мәгърифәтче Бубыйлар турында, биологиядән укучыларның белемнәре түбән. Физика фәненнән укучыларның гомуми күзаллаулары бар, ләкин физик күренешләрне фәнни терминнар белән барсы да аңлата алмаган.

Оештыру комитеты һәм жюри биргән материаллардан чыгып, БОЕРАМ:

**1. 1нче дәрәҗә диплом белән түбәндәге укучыны бүләкләргә:**
- Гобәйдуллина Раяна, Иж – Бубый урта мәктәбенең 4нче сыйныф укучысы.
- Салимуллин Булат, Иж – Бубый урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучысы.
- Фатхуллин Раяз, Әгерҗе шәһәре 2нче урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучысы.
- Гозәирова Алия, Әгерҗе шәһәре 2нче урта мәктәбенең 6нчы сыйныф укучысы.
- Касыймов Инсаф, Иж – Бубый урта мәктәбенең 7нче сыйныф укучысы.

**2. 2нче дәрәҗә диплом белән түбәндәге укучыларны бүләкләргә:**
- Сабирова Айзилә, Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиянең 4нче сыйныф укучысы;
- Закиров Камил, Тирсә урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучысы;

- Абрамов Лев, Иж – Бубый урта мәктәбенең 6нчы сыйныф укучысы.
- Шәйдуллина Агилә, Көчек урта мәктәбенең 7нче сыйныф укучысы.

**3. 3нче дәрәҗә диплом белән түбәндәге укучыларны бүләкләргә:**
- Муллахметова Диана, Тирсә урта мәктәбенең 4нче сыйныф укучысы.
- Абдуллин Зиннур, Әгерҗе шәһәре 3нче урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучысы.
- Хамидуллина Элиза, Исәнбай урта мәктәбенең 5нче сыйныф укучысы.
- Хасанов Рамазан, Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиянең 6нчы сыйныф укучысы.
- Мингазова Язилә, Әгерҗе шәһәре 2нче урта мәктәбенең 6нчы сыйныф укучысы.
- Латыпова Кәримә, Сарсак-Омга лицееның 6нчы сыйныф укучысы.
- Мөхәммәдиева Нурия, Салагыш урта мәктәбенең 7нче сыйныф укучысы.

**4. Укучыларны әзерләгән укытучыларга рәхмәт белдерергә:**
- Абзалиева А.Г. - Иж – Бубый урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы;
- Каримова Ф.Ф. - Тирсә урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы;
- Хамидуллина А.Р. – Исәнбай мәктәбенең технология укытучысы;
- Альмукаева Г.Ю. - Иж – Бубый урта мәктәбенең математика укытучысы;
- Низамбиева Р.Р. – Тирсә урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы;
- Рамазанова Г.Т. - Әгерҗе шәһәре 3нче урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы;
- Абрамова Л.Р. - Иж – Бубый урта мәктәбенең тарих укытучысы;
- Ризванова А.А. - Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиянең туган (татар) теле һәм әдәбияты;
- Сабитова Л.З. - Әгерҗе шәһәре 2нче урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы;
- Фатхуллина Г.А.. - Әгерҗе шәһәре 2нче урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы;
- Сабирова Л.Г. – Сарсак – Омга лицееның туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы. укытучысы.
- Ибраһимова Р.Х. - Иж – Бубый урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы;
- Шәйхетдинова Ә.Б. - Көчек урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы;
- Гиззатуллина В.Р. - Салагыш урта мәктәбенең туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы.

5. **Белем бирү оешмасы җитәкчеләренә түбәндәгеләрне эшләүне оештырырга:**
- Укытучыларга, үз фәннәре буенча, укучыларны олимпиадага әзерләү эшен системалы алып барырга.
- Сыйныф, мәктәп музее җитәкчеләренә, фән укытучыларына Иж – Бубый мәдрәсәсе тарихын, Мәгърифәтче Бубыйлар турында мәгълүматны, аларның шәҗәрәсен, әсәрләрен һәр мәктәптә өйрәнү эшен җайга салырга.

6. МБ җитәкчеләренә 15.12.2022 хәтле 2022 елгы биремнәр җыентыгын төзергә.
7. Олимпиаданы югары дәрәҗәдә оештырган өчен Иж – Бубый урта мәктәбе директоры Бадахшин Р.Н., мәктәп коллективына рәхмәт белдерергә.
8. Боерыкны район мәктәп җитәкчеләренә җиткерергә, нәтиҗәләрен мәгариф идарәсе сайтына урнаштырырга.
9. 2023-2024нче уку елына “Яшь белгеч” олимпиадасының тематикасын 01.03.2022 хәтле билгеләргә һәм ачык биремнәр базасын төзергә. (Җаваплы – Терентьева Л.М., Латыпова Л.Р., Салимуллина Л.Р.)

Мәгариф идарәсе җитәкчесе В.Г. Сафиуллина